Раслыйм
МБМБУ «Туймәт авылы
«Йолдыз» балалар бакчасы мөдире
______________Р.Ш.Халиуллина

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 092949DB68031DBBA85F7BE0FF787874
Владелец: Халиуллина Разида Шамиловна
Действителен: с 30.01.2024 до 24.04.2025

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе
Туймәт авылы «Йолдыз» балалар бакчасының

# 2024 – 2025 уку елына
# еллык эш планы

Педагогик киңәшмә утырышында тикшерелде һәм кабул ителде

Беркетмә № 20_ “28__” августа_____ 2024 ел.

Балалар бакчасы мөдире приказы белән гамәлгә керде

№ 24_ “_01_” сентября______ 2024 ел.

# Планның эчтәлеге

1.2023-2024 уку елы эшчәнлегенә анализ

2.Бакчаның методик темасы

3. Максаты

4. Бурычлары

5.Эшләү өчен программалар һәм методик ярдәмлекләр

6.Кадрлар турында мәгълүмат

7.Педагогик коллектив алдында торган бурычлар

8.Педагогларның һөнәри квалификация дәрәҗәсен күтәрү турында мәгълүмат

9. Тәрбияченең үз белемен күтәрү буенча иҗади эш темалары

10. Педсоветлар

11. Педагогик осталыкны үстерү

12.Консультацияләр

13. Ата-аналар белән эш

14. Күргәзмә агитацияләр

15. Бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләре

16.Ачык чаралар

17. Административ – хуҗалык эшләре

18.Сәламәтләндерү буенча эш планы

19. Мәктәп белән элемтә планы

# Балалар бакчасы эшчәнлегенә анализ

Балалар бакчасы 1988 елда ачылган.
Адресы:
423108,ТР,Чирмешән районы, Туймәт авылы, мәктәп урамы, 4 йорт.

**2023 –2024 уку елында** 1 төркем эшләде: кечкенәләр төркеме, зурлар төркеме.
Исемлек буенча: 2 бала.
Балалар бакчасы 0,39 га. җирне биләп агач койма белән әйләндереп алынган. Территориядә уен, физик тәрбия, юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү өчен мәйданчыклар бар.
Материаль – техник база канәгатьләнерлек хәлдә. Бакчада косметик төзәтү эшләре үткәрелде: бинаның стеналары агартылды, буялды, уен мәйданчыгындагы җиһазлар, спорт корылмалары ремонтланды.
Комлыкка ком кайтартылды. Каты көнкүреш калдыкларыннан участокта уен зоналары ясалды.
Бакчада чәчәкләр үстерелде.
2013 елдан Федераль дәүләт таләпләре гамәлгә керү сәбәпле Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциялегендәге “Балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү программасы”, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциялегендәге “От рождения до щколы ” программалары белән эшлибез.
Узган уку елында безнең иң зур бурычыбыз **- Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерелешле телләр тирәлеге тудыру, УМК ны нәтиҗәле файдалану аша кызыксыну тәрбияләү**. Бу бурычның актуальлеген без һәрдаим күз алдында тоттык, балалар бакчасының махсус “УМК материалларын балалар бакчасы эш практикасыны кертү, гамәлгә ашыру планы” на таянып эшләдек. УМК урыннарга барып җитүен, ничек кулланышка керүен махсус төзелгән комиссия карады. Республика буенча “Биллинговальный детский сад» конкурсы игълан ителде. Балалар бакчасына уку елы дәверендә даими чыккан УМК материаллары бирелеп барды, алар теркәлде, төркемнәргә тапшырылды, кулланышын, сакланышын тәэмин итү максатыннан чаралар күрелде.
Алга тәкъдим – УМК куллануны камилләштерергә, балаларның ана телендә иркенләп диалогик сөйләшүләренә ирешергә, аралашу белем өлкәсе бурычларын югары дәрәҗәдә тормышка ашыру, икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашу мөмкинлекләрен ачу өстендә эшне камилләштерергә. Моның өчен тудырылган шартлардан 100% эффектиф файдаланырга. Эшнең нәтиҗәлеген анализларга.
Балалар бакчасының төркем бүлмәләре һәм кабинетларының үсеш тирәлеге шушы программаларның таләпләренә туры килерлек итеп төзелде. Балаларның тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру өчен музыка – физкультура залы, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү бүлмәсе, методик бүлмә җиһазландырылган. Барлык бүлмәләр дә рациональ файдаланыла.

Балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора.

Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп төркемдә чыныктыру планы төзелде, аның буенча эш оештырылды; сәламәтлек почмагы, экскурсияләр оештырылды, анда дару үләннәре турында әңгәмәләр үткәрелде, үләннәрне танырга өйрәтелде; хәрәкәтле уеннар ечен кулланма жиһазлар тупланды; спорт төрләрен кулланып бәйрәмнәр, хәрәкәтләнү күнекмәләрен үстерү буенча күңел ачу кичәләре уздырылды. Тәрбияче көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды.

Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формулаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, үз бакчабызда үстерелгән яшелчә, ел әйләнәсендә җиләк-җимеш белән туклandырылды.

Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Һәр төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында балалар белән бергәләшеп кардан тау ясап куйдык. Кыш буе балалар рәхәтләнеп шудылар, уйнадылар.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: алар азрак авырды.

Экологик тәрбия бирү эшендә эш алып барылды. Төркемдә яшь үзенчәлегенә туры китереп, табигать почмагы төзелде. Күп күрсәтмә җиһазлар, дидактик уеннар булдырылды. Балаларга табигатьнең гүзәллеге, аның байлыгы белән таныштыру, үсемлек, хайваннарны таный белергә өйрәтү, аларга карата сакчыл караш тәрбияләү максатыннан, тәрбиячебез эшен планлы рәвештә алып барды. Белгәнебезчә балаларның сәламәтлеге, яшәеше турыдан-туры әйләнә-тирә мөхиткә бәйле. Балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып, экологик тәрбия бирү буенча еллык эш планы төзелде.

Бала иң беренче чиратта үзе яшәгән төбәкнең экологик хәлен белергә тиеш, шуның өчен дә зурлар төркемендә һәр ел фасылында табигатькә экскурсияләр оештырылды. Балалар табигатьнең төрле халәтен, бөҗәкләрне, чәчәкләрне, күк йөзен күзәттеләр, яфраклар, дару үләннәрен җыйдылар, бакча мәйданчыгын чүпләрдән арындырдылар, хайваннар белән таныштылар. Күзәтү, хезмәт аша балалар табигатьнең чисталыгын сакларга, матурлыгын күрә белергә өйрәнделәр.

Һәр ел фасылын зур оешканлык белән каршы алдык. Язын тирә-якны чистартып, апрельдә чәчәк рассадалары утыртып каршыладык. Бакчадагы язгы

эшләр белем-тәрбия бирү эшләре белән чиратлап алып барылды: язгы су юлларын ачу, стена буендагы карны чистарту, бакча мәйданын җыештыру уздырылды, чәчәкләрне тәрбияләп үстерү, сирәкләү, су сибү – болар барысы да бакча хезмәткәрләре тарафыннан эшләнде. Көзне каршылап участоктан чәчәк орлыклары, яфраклар җыйдык, мәйданны коелган яфраклардан арындырдык. Кышны каршы алганда исә, кардан сыннар ясау, кар көрәү, тубәләрне боздан, кардан арындыру кебек эшләр эшләнде, кошларга җим салыр өчен җимлекләр элдек, аларга җим салуны оештырдык, агач төпләренә салкыннан саклар өчен кар өйдек.

Балаларның экологик белемнәрен киңәйтү, тирәнәйтү максатыннан тәрбияче табигать материаллары туплап, төрле сувенирлар, паннолар ясады. Бүлмәләрдә бик күп төрле гөлләр үстердек. Тәрбияче балалар белән берлектә гөлләрне карап, тәрбияләп, гөлләрне танырга, исемнәрен әйтә белергә өйрәтте.

Бу эшләр белән бергә милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында салына. Октябрьдә “Сөмбелә” бәйрәме, ноябрь аенда өлкәннәребезгә багышланган “Әбекәем - алтынкаем” дигән бәйрәм уздырдык, анда балаларның әбиләрен чакырдык, чәй табыны янында кунак иттек. Декабрь аенда Яңа ел бәйрәменә әзерлек барды һәм бәйрәмне һәр елдагыча бик күңелле итеп үткәрдек. Мартта һәр елдагыча зурлап, ныклы әзерлек белән, Әниләр бәйрәме, Нәүрүз, Кошларны каршылау уздырылды. Апрельдә Г. Тукай туган көнен уздырдык, Бөек Җиңү бәйрәменә багышланган митингта катнаштык. Май ахырында “Сау бул, бакча” бәйрәме уздырылды, анда мәктәпкә укырга барырга тиешле балаларны озату үткәрелде. Май азагында балаларны яклау көненә багышлап “Кече Сабантуй” бәйрәме гөрләп уздырылды.

Бакчада үстерелешле тирәлек булдырып балаларның иҗади сәләтләрен тәрбияләү максатыннан бакчада сюжетлы-рольле уеннар баетылды, заманча итеп үзгәртелде, яңалары ясалды.

Алдагы уку елынада узган уку елы бурычлары өстендә эшләүне дәвам итү, ФДБС өйрәнү куелды:

1. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, тормыш иминлекләрен тәэмин итү өчен шартларны камилләштерү: сәламәтләндерү-профилактик чараларны системалаштыру, физик үсеш өчен җиһазларны барлау, хәрәкәт активлыгының бердәм режимын булдыру;

2. Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерелешле телләр тирәлеге тудыру, УМК ны нәтиҗәле файдалану аша кызыксыну тәрбияләү;

3. Федераль дәүләт таләпләренә нигезләнеп, ФДБС на юнәлеш алып балаларга белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын үстерү.

**2024-2025 нче уку елына балалар бакчасының методик темасы:**

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга  хәзерге заман технологияләрен кулланып, тәрбия һәм

белем бирү

**Балалар бакчасының төп максаты:**

Киләчәк өчен һәрьяклап үсеш алган ,белемле һәм физик яктан сәламәт балалар тәрбияләү

# Балалар бакчасында кулланыла торган программалар:

## Комплексы программалар.

1.Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева «Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы»», Москва, 2012.

2.Региональная программа дошкольного образования Р.К.Шаехова «Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы» , Казан, 2012.

## Парциаль программалар.

Н.В.Полтавцева, Н.А. Гордова «Физическая культура в дошкольном детстве» Пособие инструкторов физкультуры и воспитателей, работающих с детьми 3-4 лет. Москва. «Просвещение», 2007.

Н.В. Полтавцева, Н.А. Гордова «Физическая культура в дошкольном детстве» Пособие инструкторов физкультуры и воспитателей, работающих с детьми 2 - 3лет. Москва. «Просвещение», 2007.

Н.В. Полтавцева, Н.А. Гордова «Физическая культура в дошкольном детстве» Пособие инструкторов физкультуры и воспитателей, работающих с детьми 4 - 5лет. Москва. «Просвещение», 2007.

Н.В.Полтавцева, Н.А. Гордова «Физическая культура в дошкольном детстве» Пособие инструкторов физкультуры и воспитателей, работающих с детьми седьмого года жизни. Москва. «Просвещение», 2007.

Методическое пособие:

К.В.Закирова «Гаиләдә , балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы» , Казан, 2005

Л.Х.Дәүләтшина «Бармакларны уйнатабыз – сөйләм телен үстерәбез», Казан,Школа, 2009.

К.В.Закирова “Уйный- уйный усэбез” Казан, 2010

«Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах», Казань, 2008.

С.М. Гаффарова,Г.З.Гарафиева “Изучаем русский язык”, методическое пособие по обучению русскому языку детей дошкольного возраста, Казань  “Хэтер” 2011.

К.В.Закирова    «Балачак аланы», Казан, «РИЦ нәшрияты»,  2011.

Ф.В.Хәзрәтова , З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина  «Туган телдә сөйләшәбез» , Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012.

# **Кадрлар турында  мәгълумат**

<u>Педагоглар  саны– 1</u>

Тәрбияче – 1

<u>Белем дәрәҗәсе:</u>

Югары  – 0
Махсус урта – 1
Югары уку йортында белем алучылар – 0

<u>Категорияләре:</u>

Югары – 0
I кв.кат. – 1
Вазыйфасына туры килү – 0
Категориясез – 0

<u>Педагогик стаж:</u>

2 -  5 ел – 0
5 - 10 ел – 0
15 елдан югары – 1

## Коллектив алдында торган бурычлар:

1. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү процессын планлаштыруның мәктәпкәчә белем бирү оешмасында белем бирү программасына федераль хөкүмәт таләпләренә җавап бирерлек яңа формаларын эшебездә куллану.

2. Балаларны ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерү һәм сүз байлыгын арттыруда заманча технологияләр, мультимедиа чараларын, УМК куллану.

3.Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларны чыныктыру һәм хәрәкәт активлыгын үстерү өчен шартлар тудыру.

## Педагогларның квалификация дәрәҗәсен күтәрү турында мәгълумат

| № п/п | Ф.И.О. | Вазифасы | Белем күтәрү курслары | Аттестация узган һәм узарга тиеш вакыты | Категориясе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Халиуллина Рәзидә Шамиловна | Мөдир | 2024 | 2024<br>2029 | |
| 2. | Абдуллина Әминә Нәҗметдиновна | Тәрбияче | 2024 | 2022<br>2027 | I |

**Тәрбиячеләрнең үзбелемен күтәрү буенча**
**иҗади эш темалары**

| № | Ф.И.О. | Темалары |
|---|---|---|
| 1 | Абдуллина Әминә Нәҗметдиновна | Рус телен өйрәтүдә УМК  куллану. |

**Педагоглар киңәшмәләре**

| № | **Темасы** | **Үткәрү вакыты** | **Жаваплы кеше** | **Үткәрү формасы** |
|---|---|---|---|---|
| **1** | 1 нче педагогик утырыш<br>Тема: Балалар бакчасының яна уку елына әзерлеге. | август | Мөдир | әнгәмә, план бүлекләре белән танышу. |
| | Көн тәртибе:<br>Яңа уку елына төзелгән балалар бакчасының еллык планы белән танышу. | | Тәрбияче | әнгәмә, план бүлекләре белән танышу. |
| | Тәрбиячеләрнең перспектив планнары белән танышу. | | Тәрбияче | әнгәмә, план бүлекләре белән танышу. |
| | Татар телен өйрәтүнең программасын сайлау. | | мөдир тәрбияче | әнгәмә. |
| | | | | |
| | | | | |
| | Циклограммалар белән танышу.<br>1. Көндәлек планнар язуның формасын кабул итү.<br>2. Жәйге чорда сэлэмэтлэндеру эшенэ анализ ясау | | Мөдир Тәрбияче<br><br>Шэфкать туташы | әнгәмә<br><br>энгэмэ |
| **2.** | 2 нче утырыш<br>**Тема:** 2024-2025 нче уку елында балалар бакчасы эшчәнлегенең ФДББС на һәм УМК туры китереп үтәлешенең нәтиҗәсе. | май | Абдуллина А.Н. | |
| | Көн тәртибе:<br><br>1.Мониторинг нәтиҗәләре | | Мәктәпкә әзерлек төркем тәрбиячесе, психолог,татар теле тәрбиячесе. | язмача |
| | 2.Физкультура сәламәтлән-дерү эшенә анализ. | | Фассахова Г.Х. | язмача |
| | 3.Балалар бакчасынын яна уку елына юнәлешләре һәм бурычлары. | | Абдуллина А.Н. | язмача |

# Педагогик осталыкны үстерү

| № | Эш төре | вакыты |
|---|---|---|
| | | |
| 1 | Район күләмендә МБ ФДБС өйрәнүгә, УМК ны эштә куллануга юнәлтелгән тәрбиячеләр өчен булган өйрәтү семинарларында актив катнашу, ачык чаралар күрсәтү. | Ел дәвамында |
| 2 | Үзбелем күтәрү планнарын тулыландыру.<br>Тәрбиячеләрнең портфолиоларын тулыландыру.<br>Аттестация узу. | Сентябрь. |
| 3 | Семинарда катнашу. | Октябрь. |
| 4 | Сыннар, уенчыклар ясау буенча мастер класс. (Абдуллина Ә.Н.) | Ноябрь. |
| 5 | Район һәм зона күләмендә үткәрелгән семинар һәм конкурсларда катнашу. | Ел дәвамында |
| 6 | “Дошкольное воспитание”, “Ачык дәрес”,”Мәгариф”,”Мәгърифәт”,”Ребенок в детском саду” журналларының яңа килгән саннары белән танышу һәм фикер алышу. | Ел дәвамында |
| 7 | Семинарда катнашу. | Декабрь |
| 8 | Семинарда катнашу. | Февраль |
| 9 | Ел дәвамында эшләгән эшләр белән тәрбиячеләрнең һәм бакчаның сайтларын тулыландыру. | Март. |
| 10 | Мастер-класс:<br>1. УМК ны кулланып балаларны рус теленә өйрәтүнең эффектив юллары. | Апрель. |
| 11 | Район күләмендә үткәрелгән конкурс-семинарларда катнашу, үзебезнең эшчәнлекне матбугат битләрендә яктырту. | Ел дәвамында |

# Консультацияләр

| № | Эш барышы | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Кечкенәләр төркеме балаларының адаптация үзенчәлекләре. | Сентябрь | Абдуллина А.Н. |
| 2<br>2.1 | Федераль хөкүмәт таләпләре буенча мониторинг үткәрү.<br>Сөйләм телләрен үстерү буенча УМК ны эффектив файдалану аша балаларның диалогик сөйләмнәрен үстерү | Октябрь. | Абдуллина А.Н. |
| 3 | Татар халкының милли йолалары һәм гореф-гадәтләре. | Ноябрь. | Абдуллина А.Н. |
| 4 | Яңа ел иртәләрен уздыру буенча куркынычсызлык чаралары. | Деабрь. | Халиуллина Р.Ш. |
| 5 | “Аралашу” белем бирү өлкәсе буенча балалар һәм өлкәннәр эшчәнлеген оештыру алымнары. | Январь. | Абдуллина А.Н. |
| 6 | Интегральләшкән шөгыль – бала үсеше өчен мөһим чара. | Февраль. | Абдуллина А.Н. |
| 7 | Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы хезмәттәшлек. | Март. | Абдуллина А.Н. |
| 8 | Саф һавада балаларның сәламәтләндерү, спорт уеннары оештыру өчен шартлар тудыру. | Апрель. | Халиуллина Р.Ш. |
| 9 | Балаларның җәйге чорга сәламәтләндерү эшчәнлеген оештыру. | Май. | Абдуллина А.Н. |

# Ата-аналар белән эш

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 1. Узган 2023 – 2024 уку елында балалар бакчасының эшчәнлегенә гомуми нәтиҗә.<br>2.Яңа 2024-2025 уку елында балалар бакчасының эш планы, алдагы бурычлары.<br>3. Әти- әниләр комитеты, рәисен, сәркатибен сайлау, раслау.<br>4. Консультацияләр. | Сентябрь | Халиуллина Р.Ш.<br>Абдуллина<br>АН. |
| 2 | 1. ”Бәйрәмнәрнең тәрбияви роле”<br>2. ”Уенның балалар тәрбияләүдә роле”<br>3. Яңа ел бәйрәме кичәсе. | Декабрь | Абдуллина А.Н..<br>Халиуллина Р.Ш. |
| 3 | 1.”Гаиләдә балалар белән аралашу серләре”<br>2. ”Дөрес туклану сәламәтлек нигезе”<br>3.”Балага ни өчен уен кирәк”<br>4. Җәйге сәламәтләндерү планы. | Март<br>Май | Абдуллина А.Н. |

# Күргәзмә агитацияләр

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| **1** | Ата-аналар почмагында киңәшләр бүлеген яңартып тору. | Даими | Абдуллина А.Н. |
| **2** | Ата-аналар белән анкеталар уздыру. | Кварталга 1т. | Абдуллина А.Н. |
| **3** | Фотокүргәзмәләр оештыру. | Даими | Абдуллина А.Н. |
| **4** | Ата-аналар өчен бюллетеньнәр чыгару. | Айга 1 т. | Абдуллина А.Н. |
| **5** | Тәкъдимнәр, киңәшләр тартмасы булдыру. | Даими | Абдуллина А.Н. |
| **6**<br><br>**7** | Күчмә папка эшләү:“Саулык-зур байлык”<br>Альбомнар эшләү: “Күркәм гаиләләр”,<br>Телләрне өйрәнү УМК на нигезләнеп “Сөйли белгән – морадына ирешкән” стенд ясау | Даими<br>Март<br>Апрель | Абдуллина А.Н.<br><br>Абдуллина А.Н. |
| 8 | “Әти, әни һәм мин – спорт гаиләсе” | Май | Абдуллина А.Н. |

# Бәйрәмнәр, күңел ачу кичәләре

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | “Белем бәйрәме”, ”Олимпиадага беренче адым” спорт бәйрәме. | Сентябрь. | Тәрбияче |
| 2 | Өлкәннәр көне уңаеннан очрашу-концерт (урт,мәк.әз. төркеме)<br>“Сөмбелә” (һәр төркемдә). | Октябрь. | Тәрбияче |
| 3 | Әниләр көне (һәр төркемдә),<br>Янгын сүндерүчеләр белән очрашу (һәр төркемдә),<br>”Без музыканың дуслары” күңел ачу кичәсе (һәр төркемдә) | Ноябрь. | Тәрбияче |
| 4 | “Хуш киләсең, Яңа ел!” (һәр төркемдә). | Декабрь. | Тәрбияче |
| 5 | Кышкы спорт уеннары ярышы I класс укучылары белән (мәк.әз).<br>Күңел ачу кичәсе “Юлда йөрсәң, уяу бул!” (һәр төркемдә). | Январь. | Тәрбияче |
| 6 | «Аҗаган» спорт бәйрәме (мәк.әз.төркеме),<br>“Ватанны саклаучылар - этиләр” бәйрәме. | Февраль. | Тәрбияче |
| 7 | “Иң кадерлем - әнием!” бәйрәм иртәсе (һәр төркемдә).<br>Нәүрүз бәйрәме (уртанчылар, мәк.әз.). | Март. | Тәрбияче |
| 8 | Тукай – сабыйлар күңелендә.<br>Шигырь бәйрәме (мәк.әз.). | Апрель. | Тәрбияче |
| 9 | Җиңү бәйрәмендә катнашу (уртанчылар, мәк.әз.).<br>Хуш, сөекле бакчабыз.<br>Мәктәпкә озату бәйрәме (мәк.әз.).<br>“Сабантуй” бәйрәме (барлык төркемнәр). | Май. | Тәрбияче |

# Ачык чаралар

| № | Эш барышы | Вакыты |
|---|---|---|
| 1 | Тәрбиячеләр көнен билгеләп үтү. Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының котлау чыгышы. | Сентябрь. |
| 2 | Музыка атналыгы<br><br>Пожар куркынычсызлыгы атналыгы | Ноябрь. |
| 3 | Интернет аша уздырылган конкурсларда катнашу. | Ел дәвамыыында |
| 4 | “Юлда булсаң бул өлгер, юл кагыйдәсен нык бел!” юл йөрү кагыйдәләренә багышланган атналык. | Январь. |
| 5 | Рус теленә өйрәтү буенча белем бирү эшчәнлеген карау | Февраль. |
| 6 | Балалар бакчасында сәламәтлек саклау технологияләрен куллануның инновацион алымнары, район бакча мөдирләре семинары | Март. |
| 7 | Рус теле атналыгы. | Апрель. |

# Административ – хуҗалык эшләре

| Айлар | Мөдир каршында административ хуҗалык утырышлары | Хезмәтне саклау, куркынычсызлык техникасын саклау буенча эшчәнлек | Күзәтү-контроль төрләре | Ремонт хуҗалык эшләре | Җәмгыять белән эшчәнлек |
|---|---|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | Яңа уку елына төркемнәр комплектлаштыру, тәрбияче, тәрбияче ярдәмчеләре эш вакытлары, вазифалар бүленеше турында (бакча мөдире). Көндәлек режимны саклау, шөгыльләр вакытында, түгәрәкләр оештырганда тәрбияче ярдәмчесенең эшчәнлеге. | Хезмәтне саклау буенча җаваплы кеше билгеләү, һәр хезмәткәр белән план буенча инструктаж үткәрү, яңа кабул ителгән кешеләргә инструктаж үткәрү. Пожар куркынычсызлыгы буеча өйрәнү эвакуациясен уздыру. | Балаларның төркем тормышын оештыру өчен тудырылган шартлар. | Бакчада көзге эшләр. Ягулык сезонына хәзерлек | Үзәк шифаһанә белән хезмәткәрләрнең медосмотр торышын оештыру |
| **Октябрь** | Бакчага килгән кешеләрне кертү режимын саклау, дежур тору тәртибе белән таныштыру (бакча мөдире) | Экскурсия, прогулкалар үткәргәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау, инструктаж, журнал алып бару тәртибе | Төркем бүлмәләренең, кабинетларның чисталык торышы. | Яшелчәләрне кышка хәзерләүне тәмамлау. Бакчада эш (агач кисү, орлык җыю). | Ата-аналар комитеты төзү, рәисен сайлау, җаваплы кешеләрне билгеләү, эшне бүлешү. Җирле үзидарә белән берлектә “Өлкәннәр көнен” уздыру. |
| **Ноябрь** | Туклануны оештыру, яңа таләпләр, үзгәрешләр белән таныштыру. | Аш-су кабул иткән вакытларда куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау. | Аш-су кабул итү вакытларын, балаларның ашауларын күзәтү. | Төркем бүлмәләрендә кышка хәзерлекне төгәлләү (тәрәзәләр җылыту, яшелчә саклау урыннарын җылыту | Пожар куркынычсызлыгын саклау атналыгы уңаеннан бу юнәлештә эшне оештыру. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Декабрь** | Яңа ел бәйрәменә хәзерлек, җаваплы кешеләрне билгеләү, бәйрәм көннәрендә дежур тору графигы. | Яңа ел бәйрәмнәрен уздырганда пожар куркынычсызлыган саклау | Яңа елга участок, бүлмәләрнең бизәлеше, аларга карата таләпләр. | Уен, спорт мәйданчыклар ын, юлларны, запас чыгу юлларын кардан чистарту. | Җирле үзидәрә белән берлектә яңа елга авыл урамнарын бизәү (сыннар ясау) |
| **Январь** | Беренче ярты еллык эшкә нәтиҗә, икенче ярты елга эш планы. Отпуска графигы төзү һәм раслау (профсоюз белән берлектә). | Түбәдәге карлардан, бозлардан саклану буенча инструктаж. Җылылык режимын саклау. | Куркынычсызлы к кагыйдәләренең үтәлеше, инструктаж журналларының торышы. | Юлларны, түбәләрне, уен мәйданчыклар ын көндәлек кардан чистарту. Кышкы уеннарны оештыру өчен җайланмалар булдыру. | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү атналыгы уңаеннан бу юнәлештә эшне оештыру. |
| **Февраль** | Дәүләт надзор – күзәтү оешмаларының предписаниеләре , яңалыклар белән таныштыру. | Хезмәтне саклау буенча җаваплы кеше планы нигезендә инструктажлар уздыру. | Электр җиһазларының төзеклеге, куркынычсызлы к таләпләренә җавап бирүе. | Төркем бүлмәләрендә, башка бүлмәләрдә генераль җыештырулар уздыру. | Авыл китапханәсе белән эшчәнлек |
| **Март** | Язгы чорга эш планын раслау, җаваплы кешеләр билгеләү. Җаваплы: Сөләйманова Д.Г. | Язгы ташкын, су басуга хәзерлек, куркынычсызлы к кагыйдәләрен саклау. | Киенү, йокы бүлмәләренең чисталыгы торышы | Су басудан профилактик эшләр, канау казулар, кар тарату. | Үзәк шифаһанә белән хезмәткәрләрнең медосмотр торышын оештыру<br><br>Ата-аналар комитеты утырышы, эшләнгән эшкә анализ.<br><br>Чисталык аен башлау. |
| **Аперль** | Балаларның сәламәтлеген саклау, йөрешенә анализ ясау. Җаваплы: медсестра. | Уен мәйданчыклары нда куркынычсызлы к кагыйдәләрен саклау. | Уен мәйданчыклары нда уен, хезмәт өчен тудырылган шартлар | Бакча эшләрен башлау, түтәлләр казу-тырмалау, агачлар утырту. | Җирле үзидәрә белән берлектә чисталык аенда катнашу. |
| **Май** | Узган уку елына нәтиҗә ясау, җәйге чорга эшчәнлекне планлаштыру, | Җәйге чорга план буенча инструктаж үткәрү. | Җәйге чорга хәзерлек документлары торышы. | Территориядә касметик ремонтка хәзерлек, бакчага | Авыл Сабан туенда катнашуга әзерлек. Балаларны |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | раслау. | | | чәчәкләр, яшелчә, җиләк-җимеш утыртып бетерү. | мәктәпкә озату (ата-аналар комитеты, мәктәп коллективы) |

# Сәламәтләндерү һәм авыруларны кисәтү буенча еллык эш планы

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның физик үсешен тикшерү | елга 2-4 тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 2. | Балаларның сәламәтлек торышын күзәтү:<br>1) иртәнге фильтр вакытында;<br>2) яңа килгән балаларны кабул иткәндә; | даими | Фассахова Г.Х. |
| 3. | Физкультура шөгыле буенча балаларны сәламәтлек төркеменә бүлү. | елга бер тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 4. | Физик тәрбиянең эффектлылыгын анализлау | елга бер тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 5. | Сәламәтләндерү чаралары:<br>1. Витаминотерапия.<br>2. Фитонцидлар куллану, оксолин мазе куллану<br>3. Миндалиннарны люголь эремәсе белән майлау.<br>4. Температура үзгәрүенә карап балаларны саф һавада кабул итү<br>5. Саф һавада гимнастика үткәрү | План буенча<br>Инфекция чорында<br>Даими<br><br>Даими | Фассахова Г.Х. |
| 6. | Физик тәрбия һәм чыныктыру чаралары:<br>1. Коры уыну<br>2. Тозлы, сәламәтләндерү җәймәләрендә йөрү<br>3. Теш чистарту<br>4. Сулыш гимнастикасы<br>5. Музыкаль- ритмик хәрәкәтләр<br>6. Авазлар белән сәламәтләндерү | Даими | Фассахова Г.Х. |
| 7. | Туклану:<br>1. Меню төзү,<br>2. Әзер продукциягә бракераж үткәрү,<br>3. Тиз бозылучан продукциягә бракераж үткәрү<br>4. Натураль нормаларның үтәлешен контрольдә тоту<br>5. Кухняда санитария-гигена таләпләрен үтәүне күзәтү<br>6. Калория санау. | Көндәлек<br>Көндәлек<br>Продукция килгәч<br>Даими<br>Көндәлек<br>10 көн саен | Фассахова Г.Х. |
| 8. | Сәламәт яшәү, гигиеник тәрбия бирү бүенча санитари-агарту эшләре алып бару. | Даими | Фассахова Г.Х. |
| 9. | Гәүдә торышында, күзләрдә, ишетү органнарында килеп чыккан авыруларны контрольдә тоту | Даими | Фассахова Г.Х. |
| 10. | Гигиеник тәрбия процессларын, режим моментларын, балаларның хәрәкәт | Көндәлек | Фассахова Г.Х. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | режимын күзәтү | | |
| 11. | Балаларны медицина тикшерүенә әзерләү | График нигезендә | Фассахова Г.Х. |
| 12. | Балаларны гельминт чирләренә тикшерүне оештыру | График нигезендә | Фассахова Г.Х. |
| 13. | Инфекцион авырулар белән контактта булганнарны күзәтү | Инфекция очрагында | Фассахова Г.Х. |
| 14. | Төркемнәрдә санитария-дезинфекция режимнары үтәлешен тикшерү, җилләтү режимнарын контрольдә тоту. | Даими | Фассахова Г.Х. |
| 15. | СанПин таләпләрен үтәү буенча хезмәткәрләр белән инструктаж | Айга бер тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 16. | Генераль җыештыруны оештыру | Айга бер тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 17. | Медицина бүлмәсендә көндәлек җыештыру | Көндәлек | Фассахова Г.Х. |
| 18. | Балалар бакчасында территория чисталыгын, яшелләндерүне контрольдә тоту | Даими | Фассахова Г.Х. |
| 19. | Травматизмны кисәтү максатыннан спорт инвентарьларының төзеклеген тикшерү | Атнага ике тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 20. | Балаларның буена үлчәп, мебельләрне комплектлаштыру | Елга бер тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 21. | Хезмәткәрләрне йогышлы һәм тире авыруларына тикшерү. | Көндәлек | Фассахова Г.Х. |
| 22. | Бак. препаратларының сакланышын, температура режимын күзәтеп бару | Көнгә ике тапкыр | Фассахова Г.Х. |
| 23. | Әти-әниләр җыелышларында чыгышлар | План буенча | Фассахова Г.Х. |
| 24. | Санитар – бюллетеньнәр чыгару | План буенча | Фассахова Г.Х. |
| 25. | Тиешле документацияне алып бару | Көндәлек | Фассахова Г.Х. |

**Туймәт авылы “Йолдыз”балалар бакчасының мәктәп белән элемтә планы 2024-2025 уку елы**

| **Эчтәлек** | **Дата** | **Җаваплы** |
|---|---|---|
| Мәктәпнең "Белем көне" бәйрәмендә катнашу, мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән I сыйныф балаларын мәктәпкә озату.<br>"Мәктәп белән балалар бакчасы арасындагы эшләнәсе эшләр”нең планын кабул итү.<br>Мәктәпкә, авыл китапханәсенә экскурсия | Сентябрь | Абдуллина Ә.Н. |
| Мәктәп тематикасына караган уен зоналары булдыру (мәк.әз).<br>Мәктәпнең “Ачык ишекләр” көнендә катнашу.(Дәрес карау балалар белән УМКны кулланып. | Октябрь | Абдуллина Ә.Н. |
| Мәктәпнең башлангыч сыйныф укучыларына “Шалкан” әкиятен күрсәтү(мәк.әзер. төр.) | Ноябрь | Абдуллина Ә.Н |
| Төркем белән оештырылган эшчәнлекләрне күзәтү | Декабрь | Халиуллина Р.Ш. |
| I сыйныф балаларының әлифба бәйрәмендә катнашу.<br>Кышкы спорт уеннары ярышы I класс укучылары белән (мәк.әз). | Январь | Ікласс укытучысы, .<br>Абдуллина Ә.Н |
| Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучылары һәм мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячеләре арасында үзара дәрес карау.(Рус телен өйрәнү буенча)<br>Мәктәп музеена экскурсия. | Февраль | Абдуллина Ә.Н |
| Бакчада мәктәп укучыларының концертларын оештыру | Март | Башлангыч сыйныф укытучылары |
| Башлангыч сыйныф укучылары белән театраль эшчәнлекне оештыру. | Апрель | Башлангыч сыйныф укытучылары |
| Мәктәпкә экскурсия оештыру.<br>Соңгы кыңгырау бәйрәмендә катнашу. | Май | .<br>Абдуллина Ә.Н. |

Прошито и пронумеровано и скреплено печатью 24 листа(ов).
Заведующая ____________
« 19 » 05 2016 года

ДЕТСКИЙ САД